ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 август 2021ел № 5303

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче граждан, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында нигезләмәне, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында www.nabchelny.ru урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 275 статьясы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче граждан, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча расларга.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре

турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында www.nabchelny.ruурнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәне 2 нче кушымтада каралганча расларга.

3. Үз көчен югалткан дип таныргa:

1) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керешүче граждан тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 8 декабрендәге 7608 номерлы карары;

2) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның 2014 елның 8 декабрендәге 7608 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керешүче зат тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 29 маендагы 2568 номерлы карары;

3) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан бирелгән керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында www.nabchelny.ru урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 8 декабрендәге 7613 номерлы карары.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 10 августындагы
5303 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче граждан,
шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе
җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре турында, мөлкәте һәм
мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең)
һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм
мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында
нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә белән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче граждан, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар (алга таба – керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар) бирү тәртибе билгеләнә.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданның (алга таба – граждан) керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү бурычы, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесенең (алга таба – муниципаль учреждение җитәкчесе) керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү бурычы аларга Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 275 статьясы нигезендә йөкләнә.

3. Граждан вазыйфага эшкә кергәндә, муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керү өчен документлар бирү елыннан алдагы календарь ел өчен барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәре турында белешмәләр, граждан тарафыннан муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керү өчен документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына үзенең милек хокукындагы мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук граждан тарафыннан муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәре турында мәгълүматлар, шулай ук граждан тарафыннан муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керү өчен документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына аларның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирә.

4. Муниципаль учреждение җитәкчесе ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча, хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәре турында мәгълүматлар, хисап чоры ахырына кадәр милек хокукындагы мөлкәте турында һәм үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәре турында мәгълүматлар, аларның хисап чоры ахырына кадәр милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирә.

5. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар Россия Федерациясе Президентының рәсми сайтында урнаштырылган (сылтама шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырыла) Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган «БК белешмәләре» махсус программа тәэминатыннан файдаланып тутырылган белешмә формасы буенча муниципаль учреждение җитәкчесе һәм граждан тарафыннан бирелә.

6. Граждан яки муниципаль учреждение җитәкчесе керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында үзләренә бирелгән мәгълүматларда нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмаган яки тулысынча чагылдырылмаган яисә хаталар булган очракта, ул әлеге нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә төгәллек кертелгән мәгълүматларны бирергә хокуклы.

Граждан төгәллек кертелгән мәгълүматларны әлеге нигезләмәнең 3 пункты нигезендә мәгълүматлар бирелгән көннән башлап бер ай эчендә бирергә мөмкин.

Муниципаль учреждение җитәкчесе төгәллек кертелгән мәгълүматларны әлеге нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә бирергә мөмкин.

7. Әлеге нигезләмәнең 3 һәм 4 пунктларында каралган мәгълүматлар әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең урынбасарлары тарафыннан билгеләнә торган җаваплы вазыйфаи затларга бирелә.

8. Әлеге нигезләмә нигезендә граждан, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан бирелә торган керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар, әгәр федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр булып тора.

9. Әлеге нигезләмә нигезендә граждан, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан бирелә торган керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү, законнар нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының тармак (функциональ) органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10. Муниципаль учреждение җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар әлеге карар белән расланган тәртиптә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырыла һәм бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирелә.

11. Әлеге нигезләмә нигезендә граждан һәм муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан бирелә торган керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны җыю һәм эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затлар, аларны Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда таратуда яки файдалануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

12. Әлеге нигезләмә нигезендә бирелгән керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар һәм әлеге мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат муниципаль учреждение җитәкчесенең шәхси делосына теркәлә.

13. Әлеге нигезләмә нигезендә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар биргән граждан муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына билгеләнмәсә, күрсәтелгән мәгълүматлар аның язмача гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла, ә язмача гариза булмаганда, юкка чыгарылырга тиеш.

14. Керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирмәгән яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән очракта, граждан муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына билгеләнә алмый.

15. Муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирмәү яисә тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматлар бирү, эш бирүче ягыннан аңа карата ышаныч югалу сәбәпле, төзелгән хезмәт шартнамәсен өзү (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясындагы 1 өлешенең 7.1 пункты) яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылыкның башка төрләрен куллану өчен нигез булып тора.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 10 августындагы
5303 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында www.nabchelny.ruурнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны (алга таба – керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында www.nabchelny.ru урнаштыру һәм аларның запрослары буенча әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен билгели

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җитәкчесе (алга таба – муниципаль учреждение җитәкчесе) тарафыннан бирелгән түбәндәге мәгълүматлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында www.nabchelny.ru урнаштырыла һәм бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирелә:

1) мондый объектларның һәркайсының төрен, мәйданын һәм урнашу илен күрсәтеп, муниципаль учреждение җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукындагы яки алар файдалануындагы күчемсез милек объектларының исемлеге;

2) муниципаль учреждение җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының төре һәм маркасы күрсәтелгән милек хокукындагы транспорт чаралары исемлеге;

3) муниципаль учреждение җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының декларацияләнгән еллык кереме.

3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында www.nabchelny.ru урнаштырыла һәм бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирелә торган керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларда түбәндәгеләрне күрсәтү тыела:

1) муниципаль учреждение җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, атап үтелгән затларның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында башка мәгълүматлар (әлеге нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш);

2) муниципаль учреждение җитәкчесе хатынының (иренең), балаларының һәм гаиләсенең башка әгъзаларының персональ мәгълүматлары;

3) муниципаль учреждение җитәкчесенең, аның хатынының (иренең), балаларының һәм гаиләсенең башка әгъзаларының яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм башка индивидуаль коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар;

4) муниципаль учреждение җитәкчесенең, аның хатынының (иренең), балаларының һәм гаиләсенең башка әгъзаларының милек хокукындагы яки алар файдалануындагы күчемсез милек объектларының урнашу урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар;

5) дәүләт серенә кертелгән яки конфиденциаль булып торган мәгълүмат.

4. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасын биләүнең барлык чорында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәре рәсми сайтының www.nabchelny.ru «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштырыла һәм ел саен аларны бирү өчен билгеләнгән срок чыккан көннән башлап 14 эш көне эчендә яңартыла.

5. Әлеге нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасарлары билгели торган әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затлар (алга таба – җаваплы вазыйфаи затлар) тарафыннан, әлеге нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсенә бирелә.

6. Җаваплы вазыйфаи затлар:

1) массакүләм мәгълүмат чарасыннан запрос кергән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көнлек срокта, аның турында запрос керүгә мөнәсәбәтле муниципаль учреждение җитәкчесенә хәбәр итәләр;

2) соратып алына торган мәгълүматлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында www.nabchelny.ru булмаган очракта, массакүләм мәгълүмат чарасыннан запрос кергән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көнлек срокта, аңа әлеге нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны бирүне тәэмин итәләр.

7. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгълүматларны әлеге нигезләмә нигезендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында www.nabchelny.ru урнаштыруны һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бирүне тәэмин итүче вазыйфаи затлары, әлеге нигезләмә таләпләрен үтәмәгән өчен, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яки конфиденциаль булып торган мәгълүматларны тараткан өчен, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында www.nabchelny.ruурнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәгә кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең

____________________________________________

(муниципаль учреждениенең исеме)

муниципаль учреждениесе җитәкчесенең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар

(____ елның 1 гыйнварыннан ____ елның 31 декабренә кадәр хисап чоры өчен)

| Муниципаль учреждение җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Биләгән вазыйфасы | Милек хокукындагы күчемсез милек объектларыны исемлеге | | | Файдаланудагы күчемсез милек объектларының исемлеге | | | Транспорт чарасының төре һәм маркасы | Декларацияләгән еллык кереме, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Күчемсез милек объектының төре | Мәйданы, кв. м | Урнашкан ил | Күчемсез милек объектының төре | Мәйданы, кв. м | Урнашкан ил | | |
| | | | | | | | | | |
| Ире (хатыны) | Х | | | | | | | | |
| Балигъ булмаган баласы | Х | | | | | | | | |

Әлеге мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

«__» ________ 20__ ел ________________________________

(муниципаль учреждение җитәкчесенең имзасы)